**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәр Советы**

Азнакай шәһәре № 142-35 «20» август 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 25.12.2008 ел №111-30 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәренең бюджет процессы турында» Нигезләмә хакында» карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәренең бюджет процессы турында»гы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (23.07.2009 №140-37, 11.12. 2009 №148-40, 11.11.2010 №7-2, 20.04.2011 №27-7, 22.10.2013 №103-31, 12.08.2014 №135-40, 21.10.2015 №9-2, 09.11.2017 №67-19 карарлар редакциясенддә)

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 25.12.2018 ел, № 494-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының бюджет процессы положениеләрен Россия Федерациясенең гамәлдәге бюджет законнарына туры китерү максатында,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы шәһәр Советы

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 25.12.2008 ел №111-30 «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәренең бюджет процессы турында» Нигезләмә хакында» карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәренең бюджет процессы турында»гы Нигезләмәгә (23.07.2009 №140-37, 11.12. 2009 №148-40, 11.11.2010 №7-2, 20.04.2011 №27-7, 22.10.2013 №103-31, 12.08.2014 №135-40, 21.10.2015 №9-2, 09.11.2017 №67-19 карарлар редакциясенддә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 18.2 статья өстәргә:

«18.2. Салым чыгымнары исемлеге һәм бәяләү

1. Шәһәрнең салым чыгымнары исемлеге шәһәр Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә, муниципаль программалар һәм аларның структур элементлары, шулай ук муниципаль программаларга керми торган эшчәнлек юнәлешләре буенча төзелә.

2. Шәһәрнең салым чыгымнарын бәяләү ел саен, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, шәһәр Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Әлеге бәяләү нәтиҗәләре шәһәрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.»;

1.2. 24 статьяның 3-5 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Шәһәр бюджеты турында карар проекты буенча килештерелмәгән сораулар барлыкка килгән очракта, шәһәр Советы Рәисе карары белән килештерү комиссиясе төзелергә мөмкин, аңа шәһәр Башкарма комитеты һәм шәһәр Советы вәкилләренең тигез саны керә.

4. Шәһәр бюджеты турындагы карар проекты барлык кирәкле документлар һәм материаллар белән шәһәр Башкарма комитеты тарафыннан шәһәр Советына эшләп бетерүгә кергәннән соң өч эш көне дәвамында тәкъдим ителергә тиеш.

5. Шәһәр Советы шәһәр бюджеты турында карар проектын бер укылышта карый.».

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының бюджет, финанс, салым һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З. Шәйдуллин